ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**« 10 » ноябрь 2016 ел** **№ 22**

**Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү, аларның үтәлеше тәртибенә таләпләрне раслау хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль законның 19 статьясындагы 4 өлешенең 1 пункты, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатып алулар өлкәсендә нормалар билгеләү, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларны үтәүне тәэмин итү турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2015 елның 18 маендагы 476 номерлы карары нигезендә Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү, күрсәтелгән актларны тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар әзерләү һәм кабул итү тәртибенә беркетелгән таләпләрне расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru/.
3. Карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров

**Яңа Кырлай авыл җирлеге
Башкарма комитетының
10.11.2016ел, №22
карарына кушымта**

**Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә таләпләр**

1. Әлеге документ Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының түбәндәге хокукый актларын әзерләү һәм кабул итү тәртибенә, эчтәлегенә, үтәвен тәэмин итүгә карата түбәндәгеләрне раслый:

җирле үзидарә органнары функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләре (казна учреждениеләре дә кертеп) (алга таба - норматив чыгымнар);

муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләренә) таләпләрне билгеләү кагыйдәләре;

норматив чыгымнар;

товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә таләпләр (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләре).

2. Әлеге документның 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар Арча муниципаль районы башкарма комитетының карарлары проектлары рәвешендә Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең башкарма комитеты тарафыннан эшләнә.

Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлегенең башкарма комитеты җирле бюджет чараларын баш башкаручы булып тора һәм товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр бәяләре нормативларын һәм (яисә) бәяләрен расларга хокуклы.

4. Әлеге документның 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларына җәмәгать контроле максатларында фикер алышуны үткәрү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар әзерләү һәм кабул итү тәртибенә, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү тәртибенә карата 2015 елның 18 маендагы 6 гомуми таләпләр пункты нигезендә. "Сатып алулар өлкәсендә нормалар билгеләү, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләрне раслау турында" 476 номерлы (алга таба - гомуми таләпләр,

җәмәгать контроле максатларында фикер алышу), Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты күрсәтелгән хокукый актлар проектларын билгеләнгән тәртиптә сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштыра.

5. Җәмәгать контроле максатларында фикер алышуны үткәрү срогы сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында әлеге документның 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектлары урнаштырылган көннән алып 8 календарь көн билгеләнә.

6. Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты, әлеге документның 5 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, күрсәтелгән органнар билгеләгән срокта электрон яисә язма рәвештә кергән иҗтимагый берләшмәләрнең, юридик һәм физик затларның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында Россия Федерациясе законнары нигезендә карый.

7. Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты иҗтимагый берләшмәләр, юридик һәм физик затлар тәкъдимнәрен караган көннән алып 2 эш көне эчендә әлеге тәкъдимнәрне һәм аларга җавапларны билгеләнгән тәртиптә сатып алулар өлкәсендәге бердәм мәгълүмат системасында урнаштыра.

8. Фикер алышу нәтиҗәләре буенча, җәмәгать контроле максатларында Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты, әлеге документның 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларына үзгәрешләр кертү турында, иҗтимагый берләшмәләрнең, юридик һәм физик затларның тәкъдимнәрен исәпкә алып һәм әлеге документның 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты каршындагы иҗтимагый совет утырышларында гомуми таләпләрнең 3 пункты нигезендә карау турында карарлар кабул итә (алга таба - иҗтимагый совет).

9. Иҗтимагый Совет составына җирле бюджетларның һәм иҗтимагый оешмаларның төп бүлүчеләре керә.

10. Әлеге документның 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын карау нәтиҗәләре буенча иҗтимагый совет түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) хокукый акт проектын эшләп бетерү кирәклеге турында;

б) хокукый акт кабул итү мөмкинлеге турында.

11. Җәмәгать Советы кабул иткән карар, тиешле карар кабул ителгән көннән алып 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә сатып алулар

өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштырыла торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

12. Сатып алу объектын һәм (яисә) объектларын нигезләгәндә, әлеге документның 1 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән хокукый актларга кертелгән үзгәрешләр исәпкә алына, бюджет ассигнованиеләрен бүлүне бюджетлы планлаштыру субъектлары Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә тапшырганчы исәпкә алына.

13. Әлеге документның 1 пунктының өченче һәм дүртенче абзацларында каралган хокукый актлар Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан елга кимендә бер тапкыр яңадан карала.

14. Әлеге документның 10 пунктындагы "а" пунктчасында күрсәтелгән карар кабул ителгән очракта Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге документның 1 пунктының өченче абзацында һәм дүртенче абзацында күрсәтелгән хокукый актларны иҗтимагый совет кабул иткән карарлар нигезендә эшләп бетергәннән соң раслый.

15. Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге документның 1нче пунктының өченче һәм дүртенче абзацында күрсәтелгән хокукый актлар кабул ителгән көннән алып 7 эш көне эчендә әлеге хокукый актларны сатып алулар өлкәсендәге бердәм мәгълүмат системасында билгеләнгән тәртиптә урнаштыра.

16. Әлеге документның 1 пунктының өченче һәм дүртенче абзацында күрсәтелгән хокукый актларга үзгәрешләр кертү аларны кабул итү өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

17. Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты карары муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә карата таләпләрне билгеләү кагыйдәләрен (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләрен) раслый:

а) Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты раслаган аерым төр товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләренең) характеристикалары (үзлекләре) күрсәткечләрен билгеләү тәртибе;

б) Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты, казна учреждениеләре һәм бюджет учреждениеләре (алга таба - ведомство исемлеге) сатып ала торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләрен (шул

исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләрен) сайлап алу тәртибе;

в) ведомство исемлегенең формасын.

18. Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен раслый торган карары түбәндәгеләрне билгеләргә тиеш:

а) норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе, шул исәптән исәп-хисап формуласы;

б) Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының вазыйфасы норматив чыгымнарны исәпләү тәртибен билгеләү;

в) Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр санының һәм (яисә) бәяләренең, шул исәптән хезмәткәрләр вазыйфалары һәм (яисә) категорияләре буенча төркемләшкән нормативларын билгеләү таләбе.

19. Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты сатып ала торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә карата һәм казна буйсынуындагы учреждениеләргә карата таләпләрне раслаучы хокукый актларында түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә карата таләпләр билгеләнә торган заказчыларның (заказчыларның бүлекчәләренең) исемнәре (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең иң чик бәяләре);

б) характеристикаларын (үзлекләрен) һәм аларның күрсәткечләрен күрсәтеп, аерым товарлар, эшләр, хезмәтләр төрләре исемлеге.

20. Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты һәр хезмәткәр һәм (яисә) берничә хезмәткәр өчен билгеләнгән индивидуаль, товарлар, эшләр, хезмәтләр саны һәм (яисә) бәяләре, күрсәтелгән органнарның структур бүлекчәләре буенча нормативлар әзерли һәм раслый.

21. Арча муниципаль районының Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының норматив чыгымнарны раслый торган хокукый актлары түбәндәгеләрне билгеләргә тиеш:

а) норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләре белән исәпләү тәртибе билгеләнмәгән норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе;

б) товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр саны һәм (яисә) бәяләре, шул исәптән хезмәткәрләр вазыйфалары һәм (яисә) хезмәткәрләр вазыйфалары категорияләре буенча төркемләнгән нормативлар.

22. Әлеге документның 1 пунктының өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән хокукый актлар бер яисә берничә заказчы сатып ала торган товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә һәм (яисә) Арча муниципаль районы башкарма комитеты функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнар билгели ала.

23. Товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә һәм норматив чыгымнар тиешле заказчы сатып алу объектын һәм (яисә) объектларын нигезләү өчен кулланыла.